Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№26 (119)

25 сентябрь 2014 ел




# *Илгә – тынычлык!*

Шушы көннәрдә «КФУда тынычлык көне» уңаеннан уздырылган флешмобта уку йортыбызның кешелеккә бирелгән бәяләп бетергесез бүләге – ТЫНЫЧЛЫКны сайлаганнарын ассызыклар өчен, күк йөзенә 210 шар очырттылар. Бу чара инде берничә ел уздырыла. Аның идеясе шул: һәр кешедә бер генә мизгелгә булса да, планетабызга карата сакчыл караш уяту. Бу шарлар, бер яктан, тыныч күк йөзен символлаштырса, икенче яктан, университетыбызның 210 еллык юбилеена багышланды.



## ● Вакыйгалар эзеннән

**18-20 СЕНТЯБРЬДӘ КАЗАХСТАНДА ТР КӨННӘРЕ УЗДЫ**. ТР Президенты Р.Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация составында Казан университеты вәкилләре дә бар иде. Визит кысаларында делегация вәкилләре Татарстан һәм Казахстан предприятиеләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне тагын да үстерү, яхшырту турында сөйләштеләр.

• • • •

**21 СЕНТЯБРЬ**дә танылган рус галиме, Казан университетының Астрономия обсерваториясенә нигез салучы **В.П.ЭНГЕЛЬГАРДТ**ны **ЯНАДАН КҮМҮ ЙОЛАСЫ** булды. Чарада КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ**, ТРның беренче Президенты **М.ШӘЙМИЕВ**, РФнең Финанслар министры **А.ЛАВРОВ** һ.б. дәрәҗәле кешеләр катнашты. Әлеге вакыйга уңаеннан, КФУда 20 сентябрь көнне В.П.Энгельгардтка багышланган «Якын һәм Ерак космосны тикшерү – хәзерге торышы һәм перспективалар» исемле Халыкара семинар узды.

• • • •

**22 СЕНТЯБРЬ**дә Лондон Мәгариф институтында **КФУ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ СТАЖИРОВКА**лары башланды. Әлеге стажировкада Психология һәм мәгариф институты, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты, Тел институты, Алабуга һәм Яр Чаллы институтларыннан вәкилләр катнаша. Белем бирү программасы үз эченә заманча мәгариф өлкәсенең актуаль мәсьәләләре буенча кызыклы лекцияләрне ала. Шулай ук дөньяның әйдәп баручы университетлары белән хезмәттәшлек урнаштыру мөмкинлеге дә булачак.

• • • •

**23 СЕНТЯБРЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ** берничә **ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ УЗДЫР**ды. Ул Россия Фәннәр академиясенең Югары нерв эшчәнлеге һәм нейрофизиология институты директоры **П.БАЛАБАНОВ** белән очрашты. Җитәкчеләр үзара хезмәттәшлек итү турында сөйләштеләр. Шул ук көнне немец юрист-галим, Берлин Азат университетының элеккеге президенты, хәзерге көндә Алма-Атадагы Казахстан-немец университеты ректоры И.Герлах белән узган очрашуда ике югары уку йортының хезмәттәшлеге перспективалары турында да сөйләштеләр.

• • • •

**25-26 СЕНТЯБРЬ** көннәрендә уку йортыбызда КФУның 210 еллыгына багышланган **«XXI ГАСЫРДА ЮРИДИК ФӘН ҺӘМ МӘГАРИФ»** халыкара фәнни-гамәли конференция уза. Чарада Россия, Германия, Чехия, Кытай, Франция, Польшадан катнашучылар бар. Конференция эшчәнлегенең юнәлеше хокукның барлык өлкәләрендә дә кагылачак.

• • • •

**КФУның ЯР ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫ** студентлары шәһәрнең Башкарма комитеты һәм «Челны 1626» геопроекты ярдәме белән **«ЯЛ КӨНЕНЕҢ ИҢ ЯХШЫ ВЕЛОМАРШРУТЫ»** дип исемләнгән **КОНКУРС** оештыра. Аның кысаларында актив ял өчен иң кулай һәм уңайлы булган маршрутлар сайланачак. Конкурста катнашу өчен «VeloChelny16»сайтында теркәлергә кирәк. Гаризалар 15 октябрьгә кадәр кабул ителә.

• • • •

Шул ук көнне студентлар һәм аспирантлар арасында **КАЗАН МӘРЫ СТИПЕНДИЯСЕНӘ** дәгъва кылуга багышланган матбугат конференциясе узды. Быел әлеге конкурска 20 ел тула. Проектларны яклау ике турда уза. Катнашучылар үз идеяләрен фәннитикшеренү эше итеп әзерләргә, аңа аннотация язарга тиеш. Шулай ук фәнни җитәкчедән һәм эксперттан бәяләмә таләп ителә. Документлар әзер булгач, һәр конкурсант үз проектын тәкъдир итәчәк. Стипендиянең күләме аспирантлар өчен – 30, вуз студентларына – 20, ссуз укучыларына – 10 мең сум. Конкурста катнашу өчен гаризалар 1 ноябрьгә кадәр кабул ителә.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

## ● Белем баскычлары

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

# «IT-прорыв»ка старт бирелде

23 сентябрь көнне КФУның Актлар залында «IT-прорыв» бөтенроссия конкурсының ачылу тантанасы узды. Конкурс 24 яшькә кадәр булган яшь тикшеренүчеләрне – югары уку йортлары аспирантларын, студентларын җәлеп итә.



Инна Басыйрова фотосы

«Әлеге конкурс IT-технологияләр өлкәсендә яңа элита булдыру, технологик эшмәкәрлекне үстерүне күз уңында тотып оештырыла. Бәйгедә катнашу кысаларында туган яңа фикерләр, проектлар стартаплар рәвешендә тормышка ашырылырга мөмкин», – диде Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Р.Шәйхетдинов. Ул конкурста катнашучыларга Иннополис шәһәрендә килеп, үзләренең булачак эш һәм яшәү урыннарын карап китәргә тәкъдим итте, яшьләрне инноваторлар булырга һәм командада нәтиҗәле эшләргә чакырды.

«Бүген IT-технологияләр тормышыбызның төрле өлкәләрендә үтеп керде. «IT-прорыв» конкурсы да төрле өлкә вәкилләренең белемен берләштерер», – дип ышанычын белдерде КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Д.Нургалиев. Проректор КФУ студентларының 2013-2014 уку елында уздырылган конкурста актив катнашулары һәм җиңүгә ирешүләре белән горурлануын белдерде. Чыннан да, «IT-прорыв» конкурсы быел беренче мәртәбә генә үткәрелми. Аның узган елгысында КФУдан Вадим Паленов һәм Лилия Лазареваның эшләре дипломга лаек булды. Шуны да билгеләп үтү кирәк, «IT-прорыв»та уңышка ирешүчеләр агымдагы елның июль аенда узган «Киләчәк инженерлары» конкурсында «Росэлектроника» командасы составында чыгыш ясап, җиңү яулады. Чарада танталы төстә аларны да тәбрикләделәр.

Быелгы конкурска кабул ителгән эшләр радиоэлектроника, куркынычсызлык, медицина, мәгариф, энергетикада IT кулланылышы һәм иң яхшы мобиль кушымта номинацияләрендә көч сынашачак. «Росэлектроника» оешмасының генераль директоры урынбасары А.Брыкин әйтүенчә, быелгы конкурста катнашырга 70-ләп вуз вәкиле теләк белдергән инде. Эшләр 2014 елның октябреннән 2015 елның 15 мартына кадәр кабул ителә. Аларны tvoistartap.rura җибәрергә кирәк.

## ● Эшнең төше

Материалларны **Алинә САДЫЙКОВА** әзерләде

Без бик тиз үзгәрүчән дөньяда яшибез. Тормыш арбасыннан төшеп калмас өчен, көндәлек яңалыклардан хәбәрдар булырга, аларны вакытында кабул итәргә һәм эш рәтенә кертеп җибәрергә кирәк.

# 3Dлы КФУ!




Уку йортыбыз Мәскәүдә икенче тапкыр үткәрелә торган «ВУЗПРОМЭКСПО. Ватан фәне – индустриализация нигезе» милли күргәзмә-форумында катнашачак. Ул 30 сентябрьдән 1 октябрьгә кадәр үткәрелә. Анда илне инновацион яктан үстерү идеясе белән яшәгән һәркем: ВУЗ вәкилләре, галимнәр, әйдәп бара торган корпорацияләрнең топ-менеджментлары, студентлар, экспертлар һ.б.катнаша ала.

Чараны РФнең Мәгариф һәм фән министрлыгы, РФнең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, РФнең Икътисади үсеш министрлыгы оештыра. Күргәзмәнең стратегик партнерлары – «Ростех» һәм «Росатом» Дәүләт корпорацияләре.

Әлеге чараның төп максаты – Россия сәнәгатен модернизацияләүгә юнәлтелгән заманча һәм фәнни эшләнмәләрне демонстрацияләү, Россия икътисадының инновацион үсешен тизәйтүгә юнәлтелгән икътисадның реаль сектор оешмаларының Россия вузлары белән үзара эшчәнлеген үстерү.

Күргәзмәдә, КФУ кооперациясе белән беррәттән, республикабызның башка предприятиеләре: ТАСМА, ТНГ-групп, Нижнекамскнефтехим, Алексеевск керамикасы катнашачак. Уку йортыбыз исә анда инде икенче тапкыр катнаша. Быел да аның төрле экспонатлар куелган үз павильоны булачак. Күрсәтмәле материаллар 3d графика стилендә тәкъдир ителәчәк. «Быел экспозицияләрдә җитди үзгәрешләр булачак. Гамәлгә ашырыла торган проектларның да яңа мөмкинлекләре ачылачак. Материаллар белән турыдантуры күргәзмәдә танышып булачак», – дип билгеләп үтте КФУ күргәзмә павильонының һәм материалларының дизайны эшләүче Тимур Гыймранов.

Университетыбыз стендларында КФУның конкурентлыкка сәләтлелеккә артыру юнәлешләре урын алачак. Исегезгә төшерәбез: алар – биомедицина һәм фармацевтика; кара алтын табу, аны эшкәрү һәм нефтехимия; мәгълүмати технологияләр һәм космос; перспектив материаллар.

## ● Гыйльми совет

# Беренче утырыш

23 сентябрь көнне университетыбызда И.Гафуров җитәкчелегендә яңа уку елының беренче Гыйльми советы узды.



Инна Басыйрова фотосы

Утырыш башында **И.Гафуров М.Сәлаховның**, КФУ президенты вазифасыннан китү сәбәпле, гыйльми совет составыннан чыгуы турында әйтте. Аннары күңелле вакыйгага күчтеләр: Тышкы элемтәләр департаменты директоры **А.Крыловны** 60 яшьлек юбилее белән тәбрик иттеләр.

Гыйльми совет төп эшен хисаплау коммиссиясен сайлап, аның вазифаларын билгеләүдән башлады. Аннары утырышның гыйльми сәркатибе профессор **М.Щелкунов** профессор, төп фәнни хезмәткәр вазифаларына һәм белгечлек буенча доцент гыйльми исемен дәгъвалауга кандидатларны тәкъдим итте. Гыйльми совет вәкилләре аларны бер тавыштан сайлады.

Аннары 2014 елгы кабул итү нәтиҗәләре һәм 2015 елга кабул итүгә әзерлек турында Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.Ионенко** сөйләде. Аның сүзләренчә, быелгы уртача кабул итү баллы 76 булган. Бу узган ел белән чагыштырганда бераз гына кимрәк булса да, кабул итү дәрәҗәсенә йогынты ясамаган. Шулай ук абитуриентларның географиясе дә киңәйгән. Чит илләр белән бергә, РФнең 67 төбәк вәкиле хәзер КФУда беренче курста белем ала.

Алга таба юридик факультетта интеллектуаль хокукларны саклау буенча фәнни-мәгариф үзәк булдыру, бакалавриат һәм магистратура буенча яңа юнәлешләр һ.б. турында фикер алыштылар. Шулай ук «Казан университетының атказанган профессоры», «Россия Федерациясе югары мәктәбенең лаеклы хезмәткәре» һ.б. мактаулы исемнәргә лаек булган кандидатлар белән таныштырдылар. Алар арасында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры **Р.Җамалетдинов** («Россия Федерациясе югары мәктәбенең лаеклы хезмәткәре»), шул ук институтның доценты **К.Фәтхуллова** («РФнең югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре») дә бар иде.

Сәяхәттән кайткач

# Яңа ел һәм Санкт-Петербург?!

**Лилия ЯКУПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

«КФУның иң яхшы академик төркеме» конкурсын күпләребез хәтерли. Ямьле яз айларында оештырылып, киң колач алган әлеге конкурс нәтиҗәләрен көтеп, бик күп студентларның төн йокылары калгандыр. Шулай булмый ни?! Җиңүчеләрне бит Россиянең икенче башкаласы Санкт-Петербург шәһәренә экскурсия көтә!



Әлеге конкурс һәрдаим үсештә, үзгәрештә. «Академик төркемнең иң яхшы старостасы» – үткән елда игълан ителгән яңа номинация. Тиз арада ул популярлык казанды. Әлеге номинациядә җиңүче беренче карлыгачлар: урта курстан Психология һәм белем бирү институты студенты Миләүшә Тухфатуллова, югары курслардан Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты Лилия Якупова да Санкт-Петербург шәһәренә юллама белән бүләкләнделәр.

Һәм менә, ниһаять, көтелгән көн килде. 17 сентябрьдә юлга кузгалдык. Кызлар: «Бу яңа ел кебек, әмма көз көне генә», – дип елмаештылар. Сәяхәтебез, чынлап та, Яңа ел кебек тылсымлы булып чыкты.

Санкт-Петербургның Мәскәү вокзалында безне көтәләр иде инде. Үз, якын итеп каршы алдылар. Казаннан киткәндә, Петербургта салкынрак булыр дип курыккан идек, әмма һава торышы безгә бик мәрхәмәтле булды. Күктә кояш елмая, күзләр чагыла, йөзләрдә елмаю һәм без – Петербург урамы буйлап атлап килүче КФУ студентлары!

Корабтан балга килеп эләккәндәй, поездан төшүгә, экскурсияләр башланды. Иң әүвәл автобуста Санкт-Петербург шәһәренең үзәк өлешенә күзәтү ясадык, экскурсоводыбыз һәр бинаның тарихы, анда кемнәр яшәве белән таныштырды. Алга таба Петропавел кирмәненә, Эрмитаж музеена сәяхәт кылдык. Әкичен өч йолдызлы, 18 катлы «Азимут» кунакханәсенә урнашып, шәһәр белән танышуыбызны үзлектән дәвам иттек: Петербургның метросын «сынап» карадык.

Икенче көнебез сәяхәтләргә тагын да бай булды. Петергоф, Пушкин (Царское село) шәһәрләре белән таныштык. Гәрчә әлеге шәһәрләрне аерым исем белән атап йөртсәләр дә, алар икесе дә Санкт-Петербург составында саналалар. Без бу шәһәрләрдәге гүзәллеккә, камиллеккә сокланып, хәйран калып йөрдек. Анда хәтта яшел чирәм дә сәнгать әсәре булып тоела. Әфонтаннарны (Петергоф шәһәрендә алар 200гә якын) сурәтләргә сүз җитми, аларны үз күзләрең белән күрү, үз акылың белән тоемлау кирәк.

Петербургтагы икенче көнебез әле моның белән генә тәмамланмады. Безне теплоходта төнге сәфәр көтә иде. Шәһәрнең үзәк өлеше белән беренче көнне үк танышкан булсак та, су юлы белән барганда яңадан-яңа яклары ачылып, Санкт-Петербург каласы безне тагын да ныграк сихерләде. Теплоходта башланган төнге сәфәребезне янә үзлектән дәвам итеп, күперләрнең «аерылышуын» карарга бардык. Шәһәр халкы арасында күперләр белән бәйле рәвештә бер кызыклы ышану да бар икән. Петербургта «аерылышучы» күперләр күп, әмма барысы да түгел. «Аерылышучы» күпердә сөйгәнеңне үбәргә ярамый! Чынлап та аерылышырга мөмкинсез, дип ышана петербурглылар. Әмнә сөйгәнең белән мәңгегә бергә буласың килсә, рәхим ит – «Үбешүләр күпере» синең карамакта.

Петербургтагы соңгы көнебез Исаак, Казан Кафедраль соборларына сәяхәт белән дәвам итте. Сонынан, хәтта программага кертелмәгән булса да, Петербургта урнашкан төп мәчеткә күзәтү ясарга да өлгердек. Шулай итеп, безнең сәяхәтебез ахырына якынлашты. Петербургта соңгы төшке ашны ашаганнан соң, Мәскәү вокзалына юл тоттык. Казаныбызга кайта торган поезд кузгалып китте...

Петербург белән саубуллашканда һәркайсыбыз күңеленә моңсулык өрелде. Әмма Казаныбызга якынлашкан саен, күңелдә сөенү, горурлану хисе артты. Безнең шәһәребез дә гүзәллеге белән сокландыра, күңелне иркәли. Биредә без укыйбыз, рухи, физик яктан камилләшәбез, җиңәбез, тәҗрибә туплыйбыз. Болар барысы да, күбесенчә, уку йортыбыз диварларында тормышка ашырыла. Санкт-Петербург шәһәренә сәяхәтебез дә университетыбыз бүләге бит!

Үзеңне шундый зур югары уку йортының бер тамчысы итеп хис итү, синең сыйфатлы белем алуың, конкурс-бәйгеләрдә җиңеп, уңышларга ирешүең – аның да уңышы. Санкт-Петербург шәһәрендә онытылмаслык хатирәләр җыйган барлык студентлар исеменнән уку йортыбызның җитәкчеләренә, әлеге конкурсны турыдан-туры оештыручыларга, безнең белән сәяхәт кылган кураторларыбызга рәхмәтебезне җиткерәбез. Бу сәяхәт гади сәяхәт кенә түгел, иң элек әлеге төркемнең бердәмлеге, бербөтен булып эшләп, уңай нәтиҗәгә ирешүе, бу – белем алу да, ял да...

Милли мирас

# Көз – җыен уздырыр чак

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Кәмал театры каршындагы мәйданда узган әлеге күркәм милли-дини бәйрәмгә 400ләп кеше җыелды. «Уңышлар җыйганнан соң уза торган көзге җыеннар халык арасында аеруча бер тынычланып калу, чын күңелдән бәйрәм итү белән бәйле. Казан җыены шул мохитне халыкка җиткерүне максат итеп куйды», – дип белдерә чараны оештыручылар. Җыенны «Иман йорты» яшьләр клубы, Г.Камал театры Казан мэриясе ярдәме белән үткәрде.

Чарада катнашучылар бу көнне рәхәтләнеп ял да итте, күңел дә ачты, белем дә эстәде. Җыенга килүчеләр үткән чорларга – татар халкының шанлы вакытларына кайту мөмкинлегенә ия булды. Сәхнәдә милләтебезнең данлы тарихи шәхесләре чыгыш ясады. Алар арасында Кол Шәриф тә, Сөембикә дә, Тукай да бар иде. Әлбәттә, җыен ул ял итү урыны гына түгел. Элек-электән халык мондый җирдә үзенә рухи һәм матди байлык туплаган. Бу җыен да искәрмә булмады. Махсус оештырылган Мәгърифәт мәйданчыгында теләгән һәр кеше үзе кызык дип тапкан китапны сатып алу мөмкинлегенә ия иде. Тюльпан Миңнәҗева, мәсәлән, балаларны татарча укырга өйрәтә торган «Акыллым» проекты эшкәртмәләрен тәкъдир итте.

Ярминкәләр борын-борыннан Казан сәүдәгәрләренең, һөнәрчеләренең төп җыелу урыны булган. Җыен кысаларында оештырылган ярминкәбазар мәйданчыгы да халыкны күпләп җәлеп итте. Биредә милли ризыклар, бал, кулдан эшләнгән төрле әйберләр, алка-беләзекләр, сувенирлар сатылды. Әби-бабаларыбыз заманында кул эшләренә булган ихтыяҗны акча җитмәү, сатудагы әйбер кытлыгы белән бәйләп аңлатырга мөмкин. Бүген исә кул иҗаты күпләрнең мавыктыргыч шөгыленә әверелде. Ярминкә күргәзмәсенә урнаштырылган кулдан ясалган һәр эшләнмәдә осталарның кул һәм күңел җылысын тоярга мөмкин иде.

Чарада Казан Кремле музейтыюлыгы пыялага рәсем төшерү, яулык ябу, гарәп хәрефләре белән исем язу буенча мастер-класслар да оештырды. Җыенга килүчеләр аларда бик теләп, зур кызыксыну белән катнашты.

Җыенда иң кечкенә катнашучылар өчен дә махсус мәйдан булдырылган иде. Нәниләр биредә рәхәтләнеп уйнадылар, биеделәр, шаярдылар. Балалар Тукай әкияте герое Шүрәле белән фотога төшеп тә күңел ачты.

Казан җыенының төп сәхнәсендә 30дан артык татар җырчыартистлары чыгыш ясады. Оештыручылар фикеренчә, авыл белән шәһәр, ял белән эш, мәгърифәт белән сәнгать бер-берсен тулыландырып барган чорда милли һәм дини мәдәниятләрне берләштерүче Казан җыены халкыбыз өчен әһәмиятле һәм онытылмас чара булып китәргә тиеш. Чыннан да, халкыбызның тарихын, милли гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын онытмау һәм саклау өчен мондый бәйрәмнәрнең әһәмияте зур.

Көзнең беренче ае да үтеп бара. Инде игеннәр җыелды, бөртекләр алынды. Бергәләп җыелып, ял итсәң дә була. Нәкъ менә шуны исте тотып, Казанда быел беренче мәртәбә Казан җыены үткәрелде.




Син+Мин=БЕЗ!

Кече Уникста КФУның беренче курс студентлары өчен Активлар мәктәбе узды.

# Беренчеләр өчен – Активлар мәктәбе

Университетның Студентлар клубы оештырган әлеге чара төрле институт һәм факультетларда белем алучы беренче курсларны дуслаштыру, берләштерү, аларны уку йортының күңелле тормышына җәлеп итүгә юнәлтелде. Иртәнге 10.00нан көндезге 14.00кә кадәр катнашучылар 8 төп мәйданда шөгыльләнде.

Актив студентлар өчен бию, җыр, театр, пиар, психология юнәлешендә күнегүләр, мастер-класслар оештырылды. Тренингларны Казан университетының активистлары һәм чыгарылыш курс студентлары алып барды. Чара дустанә мохиттә узды. Остаханәләрдә күтәренке рух өстенлек итте. Нәтиҗәле көн ахырында Активлар мәктәбенең яңа вәкилләре, төркемнәргә берләшеп, остаханәләрдә алынган күнекмә-белемнәрен файдаланып, үзләрен тәкъдир иттеләр. Һәр төркем диплом һәм истәлекле сувенирлар белән бүләкләнде. Активлар мәктәбе беренчеләргә осталыкларын арттыру, сәләтләрен күрсәтү, яңа дуслар табу өчен менә дигән мөмкинлек бирде.



● Тәнгә - мунча, җангa - юк

Барыбызга да таныш хәл: ашамлыклар кибетенә ипи яки сөт алу уе белән кергәсең, ә нәтиҗәдә, бер сәгатьтән артык йөреп, тауар арбасын тутырып, кассага килеп басасың.

# Супермаркетлар алдый?!



**Диләрә БАТРШИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Беренче супермаркетлар барлыкка килүгә, сатып алучының акча янчыгын бушату хәйләсе дә уйлап табылган. Супер-, мега- һәм башка төрле маркетлар безнең тормышыбызга ныклап килеп керделәр. Алар, дөрестән дә, безгә бик кирәк. Тик теләсә нинди супермаркетларның төп максаты – сатып алучыны төрле юллар белән күбрәк тауар алырга мәҗбүр итү. Әмма! Әгәр дә без кибеткә кергәнче үк бу хәйләләр турында белсәк, акча янчыгыбыз артык бушамас иде. Шуның өчен кибеттә йөреп чыгыйк һәм ничек алдануыбызны аңларга тырышыйк.

## Тауар арбалары

Алар 1930 елда АКШта ясалганнар. Бүгенге көндә бу арбалар сатып алучыга алган тауарын җайлы гына машинасына кадәр алып чыгарга ярдәм итә, өстәвенә, аны кире кертеп куясы да юк бит. Иң мөһиме, ул арба кулланылышта гына булсын, ә сатып алучы анда нәрсә тутырасын үзе дә бик яхшы белә. Һәм, дөрестән дә, ипи алырга гына керүче арбаны ала һәм тулаем аның колына әверелә. Урын күп, шыплап тутыр гына.

***Киңәш:*** Тауар арбасы урынына кәрҗин алыгыз (бигрәк тә бер-ике ашамлык кына алырга керсәгез).

## Җиләк-җимеш һәм чәчәк «күргәзмәсе»

Супермаркетка керә-керешкә чәчәкләр исе борынны кытыклый, тиз арада күзне кызыктыра, аңны томалый. Шулай итеп, аларны сатып алырга мәҗбүр итәсе дә юк.

***Киңәш:*** Бу чәчәкләргә сокланыгыз, ләкин артык мөккибән китмәгез!

## Сөт ризыклары – иң соңгы бүлектә

Күп вакыт сөт ризыкларын супермаркетларның иң соңгы бүлекләренә урнаштыралар. Ә бит алар – иң киң кулланылыштагы ризыклар. Сөт ризыкларына кадәр барып җиткәнче, сатып алучының күзе башка әйберләргә дә төшәчәк. Кызыктырган тауарлар арбаны тутырачак!

***Киңәш:*** Әгәр дә сезгә сөт кирәк икән, ул сатыла торган урынга кыска юл белән барыгыз!

## «Свежий» ашамлыклар

Һәрбер супермаркетта яшелчә һәм җиләк-җимешләр ялтырап тора. Су сиптергән очракта тизрәк бозылуларын белсәләр дә, аларны еш кына чылаталар. Ни өчен? Чөнки сатып алучы яңа гына китерелгән ашамлыкларны алырга яра та, ә баш миендә «яңа» сүзе «ялтырап торган», «чиста өслекле» сүзләре белән бер рәттә тора.

***Киңәш:*** Яшелчә һәм җиләк-җимешләрне игътибар белән тикшерергә онытмагыз. Сөртелгән һәм чылатылган өслек ашамлыкның каралган һәм бозылган җирләрен яшерә алмый.

## Тар рәт аралары һәм талгын музыка

Игътибар итсәгез, кибетләрдә рәт аралары бик тар. Моның хәйләсе – сатып алучыларны акрын хәрәкәт иттерүдә. Бу вазифаны талгын музыка да үти. Сатып алучы акрын хәрәкәт иткәндә еш туктый, ә талгын музыка тәэсирендә йомшый һәм күз ялганына тиз бирелә.

***Киңәш:*** Кибеткә кеше күп вакытта керегез. Бу очракта сез кирәк-яракны алып, тиз генә ыгы-зыгылы кибеттән чыгып китәрсез. Яки колакча ярдәмендә анда үзегезнең музыкагызны тыңлап йөрегез.

## Бүләккә яки бушка

Сезнең берәр яңа тәмтом татып карыйсыгыз киләме? Супермаркетларда аларны бушка авыз итеп карау мөмкинлеге бар. Бушка килгән ашамлык кеше аңында һәрвакыт бүләк кебек кабул ителә. Җавап итеп, сатып алучы кызык өчен бу ашамлыкны кибет киштәсеннән тауар буларак сатып ала. Бу хәйләгә бирелмәгез!

***Киңәш:*** Исегездә тотыгыз: бушка килгән ашамлыклар бүләк түгел, ә хәйлә. Һәм сез беркемгә дә бурычлы түгелсез.

## Күз кая төшә?

Кыйммәт бәядәге тауарларны һәрвакыт күз тигезлегендәге киштәләргә куялар. Бу – бик акыллы хәйлә. Бу тауарлар балаларны җәлеп иттерү өчен еш кына аскы киштәләргә урнаштырыла.

***Киңәш:*** Күзгә ташланган һәр әйбер файдалы түгел.

## Касса янында бетмәс чират

Сезгә теләсә кайсы супермаркетта касса янындагы чират гомерлек кебек тоелмыймы? Кешеләр бик күп җыелсалар да, кассирлар бер вакытта да җитми. Бу чираттагы хәйлә: сезне шоколад, газета-журнал, дисклар һәм башка вак ашамлыклар янында озаграк бастырып тоту. Бу вакытта сезнең ашыйсыгыз яки эчәсегез килә башлый. Һәм сез, әлбәттә, янда гына торган киштәдән берәр тәм-том аласыз.

***Киңәш:*** Киштәдә торган журналны алып укыгыз, ә чиратыгыз җиткәч, кире урынына куегыз.

● Сәламәт тәндә – сәламәт акыл

# Спортчы математиклар

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

21 сентябрь көнне Н.И.Лобачевский исемендәге математика һәм механика институты «Москва» спорт комплексында традицион көзге Спорт бәйрәмен үткәрде.




Галимнәр сүзләре буенча, хәзерге көн яшьләренең интеллектуаль һәм физик үсешенә нык игътибар бирелергә тиеш. Шушы таләпләргә нигезләнеп, әлеге институт студентлары төрле мәсьәләләр, тигезләмәләр чишеп – акыл сәләтенә, ә спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше белән тән сәламәтлегенә ирешү өчен һәрвакыт гимнастика ясап тора.

2012 елда старт алган әлеге бәйрәм быел өченче мәртәбә оештырылды. Узган еллардагы кебек үк, чарада институт студентлары, укытучылар, хезмәткәрләр катнашты. Тәбрикләү сүзе белән институтыбызның социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары П.Г.Великанов чыгыш ясады. «Сәламәтлек турында кайгырту – тәрбия эшенең гаять әһәмиятле өлеше. Спорт бәйрәме – эшчәнлегебез максатларына ирешү юлында бер мизгел. Бүгенге көн һәркайсыгыз өчен дә файдалы узар, күңелләрегездә онытылмас хатирәләр калдырыр», – дип искәртеп узды ул.

Чыннан да, әлеге көн бик күңелле, үзенчәлекле, күтәренке рухта узды. Биредә мехматның иң актив, иң өлгер студентлары җыелган иде. Узган еллардан аермалы буларак, ярышларда катнашучы укытучыларның саны азрак булды, ләкин арабызда безнең өчен җан атып утыручы укытучыларыбыз шактый иде. Функцияләр теориясе кафедрасының лаборатория мөдире Л.А.Князева, хис-кичерешләре белән уртаклашып: «Искиткеч матур бәйрәм бу. Миңа бик ошый. Чара елдан-ел яңа сурәт ала, камилләшә бара. Үз студентларың өчен җан атып, үзеңә дә күпмедер дәрәҗәдә физик тәрбия аласың. Моннан мин үзем белән озакка җитәрлек позитив энергия алып кайтам».

Тәбрикләү сүзләреннән соң, җыелган командалар волейбол һәм стритбол буенча көч сынашты. Институтыбызның минифутбол буенча җыелма командасы беренче курс җыелма командасы белән күрсәтмә матч тәкъдим иттеләр. Программага, шулай ук, өстәл теннисы буенча ярышлар да кертелгән иде. Бу спорт төрендә студентлар шәхси беренчелек өчен дә көрәште. Тәнәфесләр вакытында институт активистлары тарафыннан әзерләнгән музыкаль номерлар күрсәтелде.

Авыр һәм шул ук вакытта күңелле ярышлардан соң, җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы башланды. Бүләкләр Н.И. Лобачевский ис. математика һәм механика институты дирекциясе һәм «FUN 24» күңел ачу үзәге тарафыннан әзерләнгән иде. Минемчә, арабызда җиңелүчеләр булмады, чөнки без барыбыз да – җиңүче! Дөресрәге, җиңүче – безнең институт. Безнең иң яраткан, горурланып сөйләрлек, бөек математик Николай Иванович Лобачевский исемен йөртә торган математика һәм механика институты!

Әлеге чараны оештыручыларның һәркайсына, институт җитәкчелегенә барлык студентлар исеменнән зур рәхмәтебезне белдерәбез!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.